РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Шингальчинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423554, Нижнекамский район,
с. Шингальчи, ул.Школьная, 6

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районының
Шәңгәлче авыл җирлеге
Советы

423554, Түбән Кама районы,
Шәңгәлче авылы, Мәктәп урамы, 6

тел./факс (8555) 43-04-50, электронный адрес: Shingalchinskoe.Sp@tatar.ru, сайт: www. shingalchinskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

16.05.2022 ел № 14-1

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 октябрендәге 14-1 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге Уставының 62 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Түбән Кама муниципаль районы Советына тапшыру турында килешүләрне раслау хакында» 2018 елның 17 маендагы 37 номерлы карарына таянып, Шәңгәлче авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Шәңгәлче авыл җирлеге Советының «Шәңгәлче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук «Шәңгәлче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 30 октябрендәге 14-1 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны мәгълүмат такталарында игълан итәргә һәм Шәңгәлче авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар 2022 елның 1 июнендә үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Р.Х. Салимов